ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д.64, с. Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2 -25 факс (84366 50-2-25). E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**23 декабрь 2025 ел** **№37**

**Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану
өчен рөхсәт ителгән урыннарны
билгеләү турында**

Яңа ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның гомере һәм сәламәтлеге иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне тәэмин итү максатларында, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм “Янгын куркынычсызлыгы турында”1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында” 22 декабрь 2025 елнын № 1121 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып, Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Биеклеге 50 метрдан артык булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә, һава киңлегеннән файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасының оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - Вәкаләтле орган).

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.”

2. Пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урыннар дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Наласа авылы төньяк юнәлешендәге басу, торак пункттан 300 метр ераклыкта;;

- Урта Бирәзә авылы төньяк юнәлешендәге басу, торак пункттан 300 метр ераклыкта.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР,Арча районы,Наласа авылы, М.Вахитов урамы,64 йорт,ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Наласа авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: И.Р.Шакирова